Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге

Шигали авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

от 25 февраля 2025 г. № 4

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шигали авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Шигали авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 6 номерлы (2017 елның 14 декабрендәге 19 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 11 номерлы, 2019 елның 2 октябрендәге 49 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 61 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 69 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган карары белән, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының тормыш эшчәнлеге, хокук ияләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең уңай шартларына район халкының хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге башкарма комитетына гавами тыңлаулар оештыручыларга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

3. Гавами тыңлаулар үткәрү 2025 елның 25 мартыннан да соңга калмыйча тәгалләнергә тиеш дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге
башлыгы урынбасары О.В. Маркова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ШИГАЛЕЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ ШИГАЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633000987